ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫНДА
Акча мәсьәләсендә борчылырга сәбәп юк
> 2

ХӘБИР ИБРАҺИМ:
«Талант белән генә ерак китеп булмый, әрсезлек кирәк»
> 3

ӘБИЛӘР... ТУЕ
Баулы районының Татар Томбарлысы авылы өлкәннәренең ут уйнатыр чагы
> 4

САБАНТУЙ БАТЫРЛАРЫ
Бер көрәшә башлагач, бик сирәк кеше генә туктый ала
> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 80 (28853) | Чәршәмбе | 8 июнь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

ҖИЛДӘН УЗЫП ОЧМАСКА

ЭЛЕКТР САМОКАТЫН ЙӨРТКӘНДӘ ТИЗЛЕК КЕНӘ ТҮГЕЛ, ИГЪТИБАР ДА МӨҺИМ

Хәвефсез юл

Бәрдергән дә, бәрелгән дә. Электр самокатын иярләп йөрүчеләрнең юл-транспорт һәлакәтенә очраулары хакында еш ишетергә туры килә. Җәрәхәт алу – бер хәл. Иң аянычлысы: карап торышка куркынычсыз тоелган транспорт чарасының үлемгә китергән очраклары да юк түгел. Тизлек яратканнарның гомере шулай ук бик тиз өзелергә мөмкин. Бигрәк тә – балаларның.

Баш бәласе

Көннәр җылытып, самокатлар сезоны ачылуга, Республика хастаханәсенә 49 бала мөрәҗәгать иткән. Өч бала электр самокатыннан егылып, җәрәхәтләнү алган.

– Соңгы елларда велосипед, самокат, электр самокатлары бик киң таралды. Узган җәйдә Республика клиник балалар хастаханәсенә, кичектергесез ярдәм сорап, 10 меңнән артык кеше мөрәҗәгать итте. Шуларның 1900е хастаханәгә салынды. Быел исә 38 балага стационар дәвалану кирәк булды, – ди хастаханәнең травматология бүлеге мөдире Руслан Хәсәнов.

Табибларның да, ЮХИДИ хезмәткәрләренең дә баш бәласенә әверелгән электр самокатларында саксыз кылану аяныч нәтиҗәләргә китерүен яшерми белгеч. Җәрәхәтләрнең дә бик тиз төзәлә торганнардан түгеллеген искәртә.

– Терсәк буыны, баш мие җәрәхәтләнү – төп имгәнүләр әнә шулар. Шлем, терсәкне саклый торган махсус җайланма (подлокотник) булмавы җитди җәрәхәтләргә китерә, – дип аңлата Руслан Хәсәнов.

Ә сөякне яңадан җыю – катлаулы эш. Бала организмы әле үсә, ахыргача формалашмаган, шуңа аеруча сак булырга кирәк.

– Сөякләрне яңадан, дөрес итеп җыйган очракта да, җәрәхәттән соң буыннар үз функцияләренең 10 процентын үтәмәячәк. Ата-аналарга менә шуны да аңлатырга туры килә, – ди белгеч. Тернәкләнү якынча 6–8 атнага сузылырга мөмкин. Кайбер очракта балаларга ярты еллап махсус аппарат киеп йөрергә туры килә икән әле.

Тизлеккә кызыгып

Җайлы, рәхәт, тиз. Артык көч тә, акыл да кирәкми... дисәк тә, электр самокатын куллану үзең һәм җәяүлеләр хакында уйлаудан, җаваплылыктан азат итми әле. Соңгы арада аварияләр өлешенә замана транспортлары да өстәлде бит. Быел инде сигез шундый һәлакәт очрагы теркәлгән. 10 һәм 13 яшьлек ике бала төрле дәрәҗәдә имгәнүләр алган. Җылы көннәр башланды гына, алда ни булыр?!

Илдар Мөхәммәтҗанов

Аварияләр ни сәбәпле килеп чыга соң? Татарстан ЮХИДИ идарәсенең техник күзәтчелек һәм теркәү-имтихан эшләре буенча бүлек башлыгы Дамир Бикмөхәммәтов әйтүенчә, самокатка атланган кешеләр үзләре үк юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозарга хирыс. Тыз-быз килеп торган ишегалларына, машиналар йөреп торган җиргә чыгалар, таләпләрне санга сукмыйлар.

ЮХИДИ идарәсе вәкиле искәрткәнчә, электр самокатында йөргәндә тизлеккә аеруча игътибарлы булырга кирәк. Юлга чыгар алдыннан светофорга карарга, ашыкмаска, яшел ут янганын көтәргә. Шулай ук тәнне җәрәхәтләрдән саклый торган махсус экипировка турында да онытмаска.

Җәяүлеләрдән күбрәк

Күпләр электр самокатларына атланганнарның йөрешеннән генә түгел, үз-үзләрен тотышыннан да зарлана. Әйтик, күпчелеге юл алар өчен генә түшәлгән кебек кылана. Ә бит җилдәй куып килгән самокатчыны җәяүле күреп, читкә китеп өлгермәскә дә мөмкин. Монда инде бәрелешми хәл юк.

Мондый күренешләр түрәләрнең күңеленә дә хуш килми икән. Күптән түгел «Бердәм Россия» партиясе депутаты Наталия Астахова электр самокатын иярләүчеләрдән зарланган иде. Әле чак кына бәрдерми калганнары да бар икән.

– Яшьләр самокатны ала да тротуар буенча йөри. Әле җәяүлеләргә кычкырталар да, янәсе, тротуардан китегез. Велосипедчылар да, хәзер инде самокатта йөрүчеләр дә төшенчәләрне бутады булса кирәк. Тротуарлар алар өчен ясалган, ахры, дигән хис туа, – дигән иде депутат бер чыгышында. – Тротуар буенча йөргәндә өч-дүрт тапкыр шулар белән очрашам, чак кына аяктан екмыйлар. Әле ризасызлык та белдерәләр. Тротуарлар – җәяүлеләр өчен. Моны чикләргә кирәк.

Асылда, чикләү күбрәк ризасызлык тудырачак. Бәлки, җәяүлеләргә дә, «тимер ат»тагыларга да хөрмәт культурасын булдырырга һәм бу юнәлештә эш алып бару кирәктер иң элек?

Ахыры 2 нче биттә >

Сан

- Казанда көн саен **3** меңләп кеше электр самокатын арендага алып тора.
- Былтыр арендага алып тору кагыйдәләрен бозган өчен **20** меңләп самокат иярләүчене штрафка тартканнар иде.

Бәяләр үсүдән туктады

Май аеның икенче яртысында бәяләр үсүдән туктады. Хәзер инфляция күрсәткече – нуль дәрәҗәсендә. Бу хакта Россия Президенты Владимир Путин белдерде. «Инфляцияне йөгәнләүгә ирешелде. 27 майга ул 17,4 процент тәшкил итә иде», – диде ул. Дәүләт башлыгы әйтүенчә, хакимияттәгеләр бу хәлнең уңай ягын да, тискәре ягын да күздә тотарга тиеш. «Килеп туган хәлләрне тәфсилле анализлап, үз вакытында тиешле карарлар кабул итәргә кирәк. Без шулай эшлибез дә», – дип билгеләп үтте Владимир Путин.

Теманың дәвамы 2 нче биттә >

Студентлар азрак түләячәк

Яңа уку елыннан студентларга җәмәгать транспортында юл йөрү бәясен 30 процентка киметү күздә тотыла. Республиканың яшьләр эшләре министры Тимур Сөләйманов «#ТатарстанОнлайн» программасы эфиры аша шулай дип белдерде. Аның әйтүенчә, студентларга ярдәм итү өчен «Транспорт гранты» булдырылган. Моның өчен һәр ел саен 60 миллион сум акча бирелә. Әмма ул гына проблеманы тулысынча хәл итә алмый. Министр сүзләренә караганда, грант гел «5ле»гә укучыларга, актив балаларга һәм социаль ярдәмгә мохтаҗларга гына бирелә. Шуңа күрә хәзерге вакытта министрлык башка студентларга да ярдәм итү буенча эшли. «Бүген студент транспортта барган өчен «тере» акча белән 31 сум түли. Аны өчтән бер өлешкә киметеп, 21 сумга калдыру турында уйлыйбыз», – диде Тимур Сөләйманов.

Спорт корылмалары яңартыла

vk.com

Татарстанда тугыз спорт корылмасын капиталь төзекләндерүгә республика бюджетыннан 459 миллион сум биреләчәк. Дәүләт сатып алулар сайтында бу җәһәттән тендер басылып чыккан. Алты объект Казанда урнашкан. Болар – «Динамо» стадионы, «Тулпар» һәм «Ак Бүре» спорт комплекслары, «Ак Барс» көрәш сарае, «Ак Барс Арена» стадионы һәм аның көньяк өлеше. Моннан тыш районнарда – Югары Осланның Введенская Слобода авылында ату буенча республика спорт мәктәбе, Саба районы Лесхоз авылында «Нарат» спорт комплексы һәм Буада «Арктика» спорт мәктәбе яңартылачак.

Проект заказчысы – «Главинвестстрой» 14 июньгә кадәр тендерга катнашуга гаризалар кабул итә. Төзекләндерү эшләрен 1 декабрьгә кадәр төгәлләргә кирәк булачак.

Яңалык

Бурыч чабудан тартса

Штраф белән генә котылып булмаячак. Быел алимент буенча бурычы җыелган кешеләрне җинаять җаваплылыгына да тарта башладылар. Хәзерге вакытта республикада алимент түләмичә качып йөргән 500 кешегә карата шундый катгый чара кабул ителгән. Билгеле булганча, моңа кадәр суд приставлары андыйларга штраф сала, машина йөртү хокукыннан, чит илгә чыгу мөмкинлегеннән мәхрүм итә иде.

Хәзерге вакытта Татарстанда алимент буенча бурычлары җыелган 26 меңнән артык кеше исәпләнә. 23 майдан 1 июньгә кадәр дәвам иткән «Суд приставлары – балаларга» дип исемләнгән илкүләм акция барышында суд приставлары бурычлы затлардан 16 миллион сумлык әҗәтен түләттергән. Ел башыннан бирле исә алар алимент түләмәүчеләрдән 239 миллион сумлык бурычын кайтарттырган. Бу узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда 8 процентка күбрәк. Бер ел элек шушы чорда суд приставлары бурычлылардан 220 миллион сумлык бурычын түләттергән булган. Агымдагы ел башыннан бирле республикада баласына алимент түләмәгән 1100 кеше – административ җаваплылыкка, тагын 500 кеше җинаять җаваплылыгына тартылган. «Җинаять җаваплылыгына тарту – суд приставлары тарафыннан кулланылган катгый чара. Әмма ул нәтиҗә бирә», – ди Татарстан буенча Суд приставлары федераль хезмәте идарәсе башлыгы Әнвәр Закиров.

Әле күптән түгел генә приставлар Лениногорскида яшәүче, алимент түләмичә качып йөргән ир-атка ярты миллион сум бурычын түләттергән. Җинаять эше ачкач, ир-ат бу бурычын көнендә үк кайтарган. «Быелның гыйнварыннан гамәлдәге федераль законга үзгәрешләр керде. Хәзер алимент буенча бурычын күз буяу өчен – өлешчә генә кайтарган кешегә дә җинаять җаваплылыгы яный», – ди Әнвәр Закиров.

Республикада баласына алимент түләмәүчеләрнең күпчелеген ир-атлар тәшкил итә. Әмма араларында хатын-кызлар да юк түгел. Алар барлык бурычлыларның 13 процентын тәшкил итә. Бу төркемгә, нигездә, ана хокукыннан мәхрүм ителгән яки махсус оешмаларда көн күрүче хатын-кызлар керә. Берничә көн элек суд приставлары Спас районында алимент буенча 50 мең сум бурычы җыелган ананы ун тәүлеккә тоткарлаган. Ул эшсез калуы аркасында 3,5 ай дәвамында баласына алимент түләмәгән. Мәшгульлек үзәгендә тәкъдим ителгән эш урыннарына да ризалашмаган. Хәзерге вакытта ул – махсус приемникта. «Бурычын аннан чыккач та кайтармаса, аңа карата катгыйрак чаралар күреләчәк», – ди Әнвәр Закиров.

Сүз уңаеннан, Татарстан буенча Суд приставлары федераль хезмәте идарәсе алимент мәсьәләләре буенча ай саен халыкны кабул итә. Борчыган сорауларыгыз булса, 8(843)514-92-21, 8(843)514-92-20, 8(843)514-92-18 номерларына шалтырата аласыз.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Сүзгә-сүз

Максим ТОПИЛИН, Дәүләт Думасының Икътисади сәясәт комитеты рәисе:

Бүгенге хәлләр безгә – зур сабак. Теләсә нинди хәл килеп чыгарга мөмкин бит. Шуңа күрә кайсыдыр илнең импортына гына өметләнергә кирәкми. Әмма бар нәрсәне үзебездә җитештереп бетереп тә булмый. Үзенә күрә бер критик технологияләр банкы булдырырга кирәк. Төрле тармакларга кирәкле төп технологик эшләнмәләр һәрчак кул астында торырлык булсын.

(«Татар-информ» агентлыгына биргән интервьюсыннан)

РОССИЯДӘ – СӘЛАМӘТ ТОРМЫШ

СБЕР Еаптека белгечләре Россиядә яшәүчеләрнең сәламәт тормыш рәвешенә мөнәсәбәтен ачыклаган. Аерым алганда, алар сораштыруда катнашучылардан сәламәт яшәү рәвешен алып баруда нәрсә комачаулавы турында белешкән.

52%...........акча җитми

51%............вакыт җитми

45%...........ялкаулык өстен чыга

Сөенечле хәбәр!

2022 елның 6–16 июнь көннәрендә «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» газетасына ташламалы бәядән язылып була!

П2435 җомга саны — Ташламалы бәя **423 сум 48 тиен**

гадәти бәясе – ~~488 сум 10 тиен~~

П2409 атнага дүрт тапкыр чыга — Ташламалы бәя **942 сум 18 тиен**

гадәти бәясе – ~~1099 сум 32 тиен~~

Реклама 16+

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

АМЕРИКАДА ГАДӘТТӘН ТЫШ ХӘЛ

Дөньяда энергетик кризис җәелә бара. Поляк хакимиятләре, энергия чыганакларына бәя үсүгә җавап итеп, гражданнарга урманнан коры-сары җыярга киңәш иттеләр. Вашингтонның Фарсы култыгы илләрен Мәскәүгә каршы санкцияләргә кушылырга чакыруы әлегә көтелгән нәтиҗәләрне бирми. Киресенчә, Россиянең тышкы эшләр министры Лавров белән Әр-Риядта очрашулар сериясеннән соң гарәп илләре санкцияләрдән баш тартуларын белдерделәр. Россияне ОПЕК+ килешүеннән чыгару да тормышка ашырылрык түгел дип санала. Россиядән башка картель таралачак һәм аны яңадан торгызып булмаячак дип куркалар. Дөрес, Әр-Рияд Россия сата алмаган нефть күләмен тулыландырырга вәгъдә бирә, әмма бу «кара алтын»га бәяләрнең төшүенә китерми. Инфляция исә бөтен дөньяда төп проблемага әверелеп бара. Моннан берничә көн элек АКШның финанс министры Йеллен 1980 нче еллардан соң иң югары күрсәткечкә ирешкән инфляциягә мөнәсәбәттә ялгышканын белдергән иде. Ул бәяләр күтәрелүнең кыска сроклы перспективада төп проблемага әверелүен таныды. Финанс министрының сүзләрен сәүдә министры Раймондо да куәтләде. АКШ Хөкүмәтенең югары чиновниклары төшенәләр: инфляция сызландыра һәм авырттыра торганга әйләнде. Байденның бәяләр сәясәтен америкалыларның бары тик 28 проценты гына хуплый.

Бәяләр күтәрелешенең төп ике сәбәбе бар. Беренчесе – үткән ел Байден игълан иткән коткару планы. Шул план нигезендә бюджеттан зур күләмдә акча бүлеп бирелде, бизнеска һәм гражданнарга өләшенде. Әмма АКШның югары җитәкчелеге ул план тормышка ашырылмаса, эшсезлек хәзерге 3,6 проценттан күпкә югарырак булыр иде дип саныйлар. Инфляциянең икенче этәргече – энергия чыганакларына кискен күтәрелгән бәяләр. Америкада энергия җитештерә торган куәтләр кытлыкта. Һәрхәлдә, Байден администрациясе шулай дип саный һәм илдә бу уңайдан гадәттән тыш хәл игълан ителде. «Мин, Джозеф Р. Кече – Байден, АКШ Президенты, АКШ Конституциясе һәм законнары белән хакимлеккә ия кеше... куллану ихтыяҗын канәгатьләндерерлек электр ясаучы куәтләр җитешмәү куркынычы уңаеннан гадәттән тыш хәл игълан итәм», – дип әйтелә карт лидерның белдерүендә.

Америка кризисында Россиягә каршы санкцияләр зур роль уйнаса да, Вашингтон алардан баш тартырга җыенмый. Киресенчә, өченче дөнья илләрен шул уенга тартып кертергә тели. Әмма АКШның гегемонлык дилбегәсе нык бушады соңгы айларда.

Вашингтон Трамп Кытайга каршы башлаган сәүдә сугышыннан да кире чигенергә мәҗбүр. Киң куллану товарларына элекке Президент керткән тарифларны бетереп, Кытайдан арзанлы импортка киң юл ачарга ниятлиләр.

Россиядә

ТОТРЫКЛЫЛЫКМЫ? БӘЯЛӘР ТӨШӘМЕ?

Россиядә санкцияләр бик үк табигый булмаган һәм көтелмәгән нәтиҗәләргә китерә. Байденның, океан артыннан торып, 200 сумлык доллар фаразлавы әлегә тормышка ашмады. Сум көтелмәгән дәрәҗәдә ныгыды. Дөрес, сумга кәгазь доллар сатып алу мөмкинлеге чикләнгән, сатып алганда да рәсми курстан күпкә югарырак бәядән генә табып була. Шулай да зәктән доллары биржадан арзанга сатып алу – бик мөмкин эш. АКШның Россиядәге илчесе Джон Салливан бу уңайдан Үзәк банк рәисе Нәбиуллина ханымның мактады. Сумның ныгуында Нәбиуллина ханымның өлеше күпмедер – әйтү кыен. Импортның чамасыз кимүе, ихтимал, зуррак өлеш керткәндер. Россия банклары хисабындагы долларның кәнфит кәгазенә дә тормавы турында финанс министры Силуанов әфәнде дә әйтеп өлгерде инде. Экспортерлар аз чимал сатып, күп табыш алырга өйрәнделәр. Бу нефть һәм газга гына карамый. Бриллиантлар сәүдәсен бик нык чикләгәч тә, шундый ук күренеш күзәтелде: асылташлар читкә күпкә азрак китә, доллар банк хисабына күбрәк керә. Көнбатыш санкцияләре Россия банкларын халыкара түләүләр системасыннан өзеп, товар белән тәэмин итлмәгән долларга баетты безне. Хәтта Россия белән хезмәттәшлек итәргә атлыгып торган илләр дә, акча күчерү кыенлыкларын сәбәпле, безгә товар сатуда авырлыклар кичерәләр. Валютаны тәэмин ителгән акчага әйләндерү бурычын үтәми торып, аның икътисад өчен файдасы юк. Бурыч исә сәясәтчеләр тырышлыгы белән генә хәл ителә ала. Санкцияләр астындагы башка илләрдән аермалы буларак, без долларны капчыклап ташып та сәүдә итә алмыйбыз, чөнки кәгазь акчаны бирмиләр. Чималны сумга сату да коткара алмый, чөнки теге як безгә үз товарын сумга бирми. Америкаңнардан бәйсез түләү системасы булдыру юлы белән чишәргә омтылып була мәсьәләне. Петербург икътисади форумында Төркия, Венесуэла, Россия вәкилләре шул хакта сөйләшергә ниятлиләр дигән хәбәр бар. Әмма түләү системасы янкилардан бәйсез эшли алсын өчен яңа резерв валютасы булдырырга туры киләчәк. Ул мәсьәләне бары тик алтын стандарт кертеп кенә хәл итеп була.

Әлегә килеп туган вазгыятьтә икътисадны алга этәрерлек уңай мизгелләр дә шәйләнеп китә. Санкт-Петербург биржасында бензин бәясе кискен төште: бер литры 27 сум гына тора. Дөрес, ягулык салу станцияләрендә андый түбән бәяләр очратып булмый әлегә. Әмма мотор ягулыгына бәя төшеү – хәзер бик мөмкин эш. Арзанлы ягулык икътисади үсеш өчен этәргеч була ала. Санкцияләр нәтиҗәсендә йөк ташу бәяләре кискен түбәнәйде. Транспорт чыгымнарының товар бәясендә шактый урын алып торуын исәпкә алганда, бу да өлешчә дефляциягә китерә ала. Бәяләрнең гомуми төшүе чынбарлыкка әйләнсә, зарланучы компанияләргә дә бөлгенлек янамас иде. Үзәк банк бу атнада төп ставканы янә төшерергә җыена. Монысы да – уңай күренеш. Пенсия фонды белән Социаль иминиятләштерү фондын бергә кушу киләчәктә социаль түләүләрне 1,5 тапкыр арттырырга мөмкинлек бирәчәк дигән рәсми хәбәр дә бар. Бу идарә аппаратын реаль кыскарту акча басмый гына да керемнәрне арттыру мөмкинлеген аңлата. Димәк, салымнарны киметеп тә була дигән сүз. Элекеле чараларның тулы комплексын тормышка ашырганда, сумны, чынлап та, нык валютага әйләндерү мөмкин. «Санкцияләр безне көчле итә» дип менә шул чакта әйтеп булачак. Чикләүләр әлегә Россия икътисадын шул юнәлешкә этәрә. Мөмкинлекләр файдаланырмы, юкмы – анысын киләчәк күрсәтер.

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

ЛИДЕРЛАР АРТА

tatarstan.ru

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Хөкүмәт йортында «Россия лидерлары» идарәчеләр бәйгесе җиңүчеләре белән очрашты.

Бәйгенең суперфиналында республикадан җиде кеше катнашкан, шуның өчесе җиңгән. Болар – «Альфа-Банк»ның IT буенча идарәче директоры Рафаэль Вәлиев, «Мәгариф культурасы» оешмасының шәхси мәктәпне гамәлгә куючы Тимербулат Самерханов, «Таттелеком» мәгълүматлар белән идарә итү үзәге башлыгы Михаил Фокин.

Бәйгедә җиңүчеләр Татарстанның идарәчеләре резервына керергә тиеш дип белдерделәр. Рөстәм Миңнеханов аларның бу теләген хуплады. Бу егетләр ел дәвамында республиканың идарәчеләр резервы командасында белемнәрен чарлаячак. Моннан тыш Татарстанны социаль-икътисади яктан үстерүгә юнәлдерелгән проектларны гамәлгә ашырачак.

Проектта катнашучылар очрашу барышында бәйге финалында алган тәэсирләре белән уртаклашты. Президент алар белән остазлык программасы кысасында очрашырга теләк белдерде.

Шуннан соң Рөстәм Миңнеханов идарәчеләр резервының яңа составы белән очрашты һәм һәркайсын котлап, нәтиҗәле эшләүләрен теләде.

Президент каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты башлыгы Александр Белов әйтүенчә, кадрлар резервына керүгә 242 кеше теләк белдергән. Шуларның 26сы сайлап алынган. Моннан тыш «Россия лидерлары» бәйгесенең суперфиналына чыккан 7 кеше, шул исәптән 3 җиңүче резервка керә. Аларның барысы да, махсус белемнәр үзләштерүдән тыш, оешма һәм предприятиеләрдә дәүләт хакимияте органнары һәм муниципалитетларда стажировка узачак.

Идарәчеләр резервына керүчеләр министрлыкларда, муниципалитетларда яки аларның карамагындагы оешмаларда җитәкче вакансияләре пәйдә булганда, кандидат сыйфатында карала. Татарстан Президенты Указында кадрлар резервына керүчеләрнең (исемлектә алар – 192 кеше) идарәче вазыйфага өстенлекле рәвештә билгеләнергә тиешлеге турында әйтелгән.

Очрашуда Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, Премьер-министр Алексей Песошин, башка рәсми кешеләр катнашты.

Үзебезнеке булсын

Соңгы арада бу сүзләр актуальләшә. Татарстанның импортны алыштыру юнәлешендә сәнәгать өлкәсенә кагылышлы тагын бер яңалыгы бар.

КФУның матбугат үзәге

КФУ галимнәре, «Инжехим» җәмгыяте һәм «Ахмадуллины» фәнни-технологик үзәге белгечләре авиация һәм ракета-космос сәнәгатендә кулланыла торган махсус материал – полифениленсульфид (ПФС) полимеры ясауның уникаль технологиясен тәкъдим итте. Әлеге материалның төп үзенчәлеге – аның югары температураларга чыдам булуында.

ПФС материалы Япония, Көньяк Корея, АКШ һәм Кытайда җитештерелә. Россиядә Татарстан тәҗрибәсе – беренче. «Моңарчы бар белгәнебез импорт иде. Мин аны култык таяклары белән чагыштырам. Инде менә аларны читкә куеп, үз аягыбызга басар чак җитте. Ни өчен әлеге материал Татарстанда моңарчы ясалмады, диярсез. Сәбәбе гади: безнең республикада хлор җитештерелми. Аны читтән кертергә туры киләчәк. Әйтик, Башкортстаннан һәм Волгоградтан», – диде журналистларга «Татнефтехиминвест-холдинг» җәмгыятенең генераль директоры Рафинат Яруллин.

Белгечләр әлеге технологияне Россиянең Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы заказы буенча 1,5 елда әзерләп өлгергән. «Инжехим» җәмгыяте җитәкчесе Мансур Фәррахов сүзләренчә, мондый катлаулы эш өчен бу – бик кыска вакыт аралыгы.

– Россияне импорт алыштыру өлкәсенә кагылышлы бик зур эшләр көтә. Безгә соңгы елларда җитешсезлекләребезне хәл итәргә кирәк. Без нәкъ менә шул юнәлештә эшлибез. Һәм, алдыбызга тагын да катлаулырак бурычлар куеп, эшчәнлегебезне дәвам итәргә әзер. Безнең моның өчен мөмкинлекләребез бар, – диде ул.

Технологияне булдыру өчен якынча 200 миллион сумнан артык акча тотылган. Әлегә ул тест режимында эшли. Әмма сәнәгать базарында зур кызыксыну уятырга өлгергән инде.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

Татарстан Республикасы Президентының «Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы һәм Украина территорияләрендә уздырыла торган махсус хәрби операциядә катнашулары нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) Россия Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләре хәрби хезмәткәрләренең һәм аларда хезмәт иткән затларның гаилә әгъзаларына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында

2022 елның 24 февраленнән Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы һәм Украина территорияләрендә уздырыла торган махсус хәрби операциядә ирекле рәвештә хәрби бурыч үтәгән, әлеге махсус хәрби операциядә катнашулары нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаилә әгъзаларына матди ярдәм күрсәтү максатларында **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Президентының «Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы һәм Украина территорияләрендә уздырыла торган махсус хәрби операциядә катнашулары нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) Россия Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләре хәрби хезмәткәрләренең һәм аларда хезмәт иткән затларның гаилә әгъзаларына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү турында» 2022 елның 4 апрелендәге ПУ-233 номерлы Указына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) түбәндәге эчтәлекле яңа 5 нче пункт өстәргә:

«5. Әлеге Указның гамәле даирәсенә 2022 елның 24 февраленнән Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы һәм Украина территорияләрендә уздырыла торган махсус хәрби операциядә ирекле рәвештә хәрби бурыч үтәгән, әлеге махсус хәрби операциядә катнашулары нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаилә әгъзаларын кертергә.»;

б) 5 нче пунктны 6 нчы пункт дип санарга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына үз актларын әлеге Указга туры китерергә, шулай ук аның үтәлешен тәэмин итә торган башка карарлар кабул итәргә.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2022 ел, 07 июнь
№ ПУ-400

Җилдән узып очмаска

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Истә тот!

Билгеле булганча, электр самокатында хәрәкәтләнү тизлеге сәгатенә 20 чакрымнан артмаска тиеш. Моннан тыш башкала урамнарында өстәмә чикләүләр бар: Казан урамнарының 45 участогында хәрәкәт тизлеген сәгатенә 15 чакрымга кадәр чикләделәр. Тротуарларның 440 участогында ул сәгатенә – 10 чакрым. Автомобиль юлы саналган 39 участокта самокат белән хәрәкәт итү гомумән тыела. Юл аркылы чыкканда, самокаттан төшәргә туры килер.

Юл йөрү кагыйдәләре буенча, электр самокатында хәрәкәтләнүчеләрдә яктылык кайтаручы элементлар булырга тиеш. Самокатта 16 яшькә кадәрге балалар, шулай ук исерек хәлдә һәм наркотик кулланган затлар йөрергә тиеш түгел. Шулай ук бер транспорт чарасына ике кеше утыру да тыела.

УҢАЙ ЯКЛАРЫ

- Җәмәгать транспортында йөрергә яратмаган кешеләр өчен җаһәт транспорт чарасы.
- Прокатка алып тору бәясе кулай.
- Экологиягә зыян китерми.
- Башка транспорт чаралары йөрмәгән урыннарга да керә ала.

ТИСКӘРЕ ЯКЛАРЫ

- Тәгәрмәчләренә игътибарлы булырга кирәк. Чокыр-чакырлы, ташлы урыннарны бу транспорт чарасы бик сөйми.
- Аккумуляторы мәңгелек түгел. Ягулык якмаса да, электр самокаты да «ашарга» сорый.
- Яңгырлы һава торышында кулланмаска киңәш ителә.
- Электр самокатына атланган кешене күрү кыенрак. Алар велосипедчылар кебек ерактан ук шәйләнми.

ТР Дәүләт Советында

Депутатлар сессия утырышына әзерләнә. Парламент комитетлары Дәүсовет бинасында да, Татарстан районнарында да, хәтта Башкортстан җирендә дә утырышлар үткәрделәр.

7 июньдә исә Бюджет, салымнар һәм финанс комитетында республика бюджеты турында зур сөйләшү булды. «Зур» дип әйтү аңлашыла, чөнки бюджет турында закон – яшәешебезнең кай якка барасын билгели торган иң әһәмиятле документ.

Акча мәсьәләсе, гадәттә, шау-шу куптара инде ул, әмма комитет утырышы шактый тыныч узды. Татарстан финанс министры Радик Гайзатуллин узган 2021 елны безнең өчен тотрыклы булды дип бәяли. Аннан алдагы ел белән чагыштырганда бюджет керемнәре 80 млрд сумга арткан. Тупланма бюджетның керем өлешенә җыелган акча 410,9 млрд сум тәшкил итә. Шул исәптән, салым һәм салымныкы булмаган керемнәр –336,1 млрд сум.

Әлбәттә инде, иң зур салым чыганагы – нефть тармагы. Икенче урында – физик затларга салым, аннан тупланма бюджетка 98,2 млрд сум акча кергән. Керемнәрнең тагын бер чыганагы – кире кайтарылмый торган акча. Узган ел ул 75 млрд сум тәшкил иткән, 73,5 млрд сумы – федераль бюджеттан. Шунысы әһәмиятле: «Мәскәү акчасы» аерым максатлар өчен бирелә һәм алар тиешле тармакларга тулысынча җибәрелгән дә.

tatarstan.ru

АКЧА ЯКЛАРЫ

Комитет рәисе Леонид Якунин да бюджет үтәлешеннән канәгать иде: «Кабул ителгән барлык программалар финансланды», – диде ул. Шул ук вакытта тынычланырга ярамавын да искә төшерде. Чөнки һәр елыбыз проблемалар тудыра тора. Ул пандемия афәтен, Россиягә карата пакетлап-пакетлап кулланылган санкцияләрне күз алдында тота иде. Шулай да Леонид Якунин 2021 елны соңгы өч ел эчендә безнең өчен иң уңышлысы дип саный.

Министр Радик Гайзатуллин бу елның беренче кварталында бюджет үтәлешенә дә тукталды. Өч ай эчендә Татарстанның тупланма бюджетына салым һәм салымныкы булмаган керемнәр 34,5 млрд сум тәшкил иткән. Кире кайтарылмый торган акча – 8,1 млрд сум, шуның 6,9 миллиарды – федераль бюджеттан.

Министр, сүз уңаеннан дигәндәй, быелның 5 аенда бюджет үтәлешенә дә тукталды. Тупланма бюджетка кергән салым һәм салымныкы булмаган акча 173,5 млрд сумга җиткән.

Депутатлар бюджет акчасының чыгым өлеше белән дә кызыксынганнар иде. Министр әйтүенчә, чыгымнар кимемәячәк, барлык тармакларга акча тулысынча җибәреләчәк.

Бюджет тикшергәндә Медицина иминияте фонды эшчәнлеген тәлгә алмый калмыйлар бит инде. 2021 елда фонд керемнәре – 67,4 млрд сум, ә чыгымнары 67,096 млрд сум тәшкил иткән. Димәк, фонд елны профицит (336,9 млн) белән тәмамлаган. Быелның беренче кварталында фондка 20 млрд сум акча кергән, ә чыгым 13,5 млрд сум икән.

Җыеп әйткәндә, акча мәсьәләсендә хәзергә борчылырлык әллә ни юк. Татарстанның дәүләт бурычына килгәндә, узган ел нәтиҗәләре буенча ул 96,6 млрд сум тәшкил итә. Аның 89 проценты федераль бюджеттан озак срокка алган кредит акчасы. Бу санны ишетү дә кәефне төшермәде, «бурычлы үлмәс» дип юкка гына әйтмиләрдер, диюем.

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

ХӘБИР ИБРАҺИМ: «ИҖАТ ИТҮ ӨЧЕН ГАЗАП ЧИГӘРГӘ КИРӘК»

Бүген татар драматургиясе ни хәлдә? Камал, Тинчурин театрлары заманча әсәрләргә теләп алынамы? Яшь иҗатчыларга мөнәсәбәт нинди? Шагыйрь, язучы һәм драматург Хәбир ИБРАҺИМ белән әнә шулар хакында сөйләштек.

Чулпан Гарифуллина

:: Бүген иҗат кешесен танысыннар, күрсеннәр, әсәрләрен укысыннар өчен иҗат итү генә җитми. Килешәсезме?

– Анысы шулай, тик иҗат итүче кеше моның турында уйламый. Башың иеп, миңа игътибарыгызны арттырыгыз, мине күрегез, дип ялварып йөрсәң, берни дә килеп чыкмаячак. Иҗат итү ул – бер нәрсә, ә менә аны тормышка ашыру шактый авыр.

Әрсезлегең булмаса, талант белән генә еракка китеп булмый. Әрсезлек һәм тырышлык кирәк. Кайсыдыр дәрәҗәдә оятсызлык та кирәк. Ансыз булмый. Хәзер бит заманасы шундый.

:: Иҗат белән генә тормышны алып барып буламы соң?

– Әлбәттә, иҗат белән генә тормышны алып барып булмый. Бәлки, кайсыбер драматурглар алып та бара торгандыр. Күпмедер дәрәҗәдә мин дә алып бардым. Иҗат ул – минем һөнәрем. Акча китергәч, «миңа шушыны язган өчен түлиләр икән» дип сәерсенеп тә куям инде (*көлә*).

:: Пандемия иҗат кешесенә зур сынау булды. Әйтик, драматургларның әсәрләре куелмады, димәк, акча түләнмәде. Бу иҗат кешесенең якланмавын тагын бер кат дәлилләде. Сезнеңчә, менә шундый хәлләрдә нинди яклау механизмы уйлап табып була?

– Бер караганда, дәүләт безне якламый дип әйтеп булмый. Беренчедән, ул безнең әсәрләрне сатып ала. Икенчедән, үзебезнең китап нәшриятыбыз бар. Башка илләрдә бушлай китап чыгару дигән әйбер бөтенләй юк бит. Әле менә «Ышанма күз яшьләренә» дигән китабым чыгарга тора. Үзем җитәкләгән ТАИС оешмасы да авторларны яклый. Авторларга композиторлар да, рәссамнар да, сценографистлар да керә. Аларның әсәрләре театрларда куела, без шуларны контрольдә тотабыз һәм аларга акча күчерәбез. Бу да яклау бит инде.

:: Плагиат мәсьәләсендә ярдәм итә аласызмы?

– Плагиат мәсьәләсе буенча әле моңарчы сораулар булмады. Аны ачыкларга бик авыр бит. Ияреп язу дигән әйбер бар. Плагиат бит ул – күчереп язып, кеше әйберен урлау дигән сүз. Ул бик сирәк була. Ияреп язу кабул ителә. Мин «Унөч урындык, яки Шаян Шамский маҗаралары» дигән романымны «Двенадцать стульев» әсәренә нигезләнеп яздым. Ул – шушы романга пародия, плагиат түгел. Романны, повестьны урлап булмый бит инде аны. Идея урлау плагиатка керми.

:: Әсәрләрегез кайда куела? Ни өчен Камал, Тинчурин театрларында әсәрләрегез юк?

– Минем әсәрләремне халык театрлары куя. «Ялгыз каен күзе»н туксан халык театры куйды. Тинчурин театры ике әсәремне сәхнәләштерде. Ә менә Камал театры берне дә куймады. Бу сорауны миңа бик күп бирделәр инде. Режиссерлар белән уртак тел таба алмыйбыз, димәк. Фәрит Бикчәнтәевтән: «Мине кайчан куясың?» – дип сорагач, «Синең вакытың җитмәгән әле», – дип җавап биргән иде. Ярар, мин әйтәм, әти 93тә генә үлде, әле вакытым бар. Мин беркайчан да ялынып йөрмим. Әзрәк горурлыгым бар бит инде.

:: Туфан абый кебек драматург булырмы киләчәктә?

– Булыр, нишләп булмасын?! Туфан абыйның көче нәрсәдә иде? Беренчедән, ул тормышны яхшы белде. Күбесенчә авылда яши иде. Хәзер бит язучылар авылга да кайтмый, кеше белән аралашмый. Туфан абый һәр күргәнен язып барды. Аның геройлары да аерылып тора. Аларның һәрберсенең үзенең холкы, үз теле, үз фикере. Икенчедән, Туфан абый тормыштан алып язды. Шуңа күрә аның әсәрләре хәзерге көндә дә актуаль. Алар беркайчан да картаймаячак. Туфан Миңнуллин – бөек драматург. Моны инкарь итеп булмый. Без аңардан күп нәрсәгә өйрәнергә тиешбез.

:: Үзегезне «Мин – шәп драматург» дип әйтә аласызмы?

– Мин драматург кына түгел бит әле, мин – шагыйрь дә, прозаик та, публицист та, тәрҗемәче дә. Бәлкем бик тыйнак та булмас, әйтәм инде: бүген Хәбир Ибраһим театры ачсалар һәм анда фәкать минем әсәрләремне генә куйсалар, ул театр бер ун ел рәхәтләнеп яшәячәк. Халык йөриячәк. Чөнки мин халык өчен язам. Мин беркайчан да Мәскәү авторларының әсәрләрен алып, кәләпүш кидереп язмыйм, үземнекен язам.

Шигырьне яисә проза әсәрен аны бит яздың да аттың, ә пьесаны халык махсус карарга килә, акчасын түли. Ул синең әсәреңнән канәгать калырга тиеш. Мелодрама икән – елап, чистарынып, пакьләнеп, комедия икән – рәхәтләнеп көлеп, күңел ачып, «эх, тагын бер киләсе иде бит» дип чыгарга тиеш. Менә шул вакытта гына драматург шәп һәм бәхетле була.

:: Бүгенге драматургия белән танышып барасызмы? Яшь иҗатчыларга ничек карыйсыз?

– Яшь иҗатчылар булу бик сөендерә. Безнең дәвам бар дигән сүз бу. Поэзиядә Рүзәл Мөхәммәтшин, Лилия Гыйбадуллина, Булат Ибраһим кебек көчле шагыйрьләр бар. Драматурглар арасында Илгиз Зәйниевкә тиңләрлек яшьләрне күрмим әле. Мин үзем әдәбиятка соңлап, утыз яшьләр тирәсендә генә килдем. Ул вакытта бездә әрсезлек дигән әйбер юк иде. Бүгенге яшьләр шактый әрсез. Алар яшендә без премия, ниндидер исемнәр турында бөтенләй уйламадык, хәтта белмәдек тә. Ә бүген бер китап чыгаралар да исем артыннан чабып йөриләр. Менә монысы көендерә. Әле иҗатың белән халыкка танылмыйча, үзеңнең рухыңны канәгатьләндерерлек әсәрләр язмыйча, премия артыннан чабып йөрү дөрес әйбер түгел. Мин беренче премияне иллене узгач кына алдым. Язарга кирәк башта. Тема юк, диләр. Аларның бит әле тормыш тәҗрибәләре юк. Иҗат итү өчен яшәргә, ниндидер газап чигәргә, кайдадыр ялгышырга, хәтта абынырга кирәк. Кирәк өчен генә язган әсәр ул ышандырмый, ихлас булмый. Күңелеңнән нәрсә чыга, шуны язарга кирәк. Шул вакытта гына ул халыкка барып җитә.

:: Театрда яңа юнәлешләр популярлык җыя. Алар турында нәрсә әйтә аласыз?

– Хәзер театрлар лаборатор спектакль дигән әйбер белән мавыга башлады. Дөресен генә әйткәндә, ул спектакльләрне халык карамый, аңламый да. Мин моны театр җитәкчеләренә дә әйттем. Театрда иң беренче чиратта традицион әсәрләр куелырга тиеш. Бу лаборатор спектакльләр икенчел булырга тиеш. Халыкны биздерергә ярамый. Моңа безнең хакыбыз да юк. Бөтен репертуарны лаборатор спектакльләргә төшереп калдыру – кабахәтлек. Милләтне үстерү турында сөйләшәбез икән, без иң башта тамашачы турында уйларга тиеш.

:: Бүгенге вазгыять, хәзерге хәлләр турында язасызмы?

– Сиксәненче елларда коммунизмны, коммунистлар партиясен мактап күп яздылар. Туксанынчы елларда, партия җитәкчелек итүдән туктагач, шул язучылар милләт турында яза башладылар. «Кызыл»дан «яшел»гә әйләнделәр. Мин коммунистлар турында да, милләт турында да язмадым. Минем үземнең темам бар, мин һәрвакыт шуның белән бардым. Милләт өчен газап чикмичә, ничек милләт турында язарга була? Безнең милләтнең рухи кыйммәтләре турында әле генә яза башладым. Күбрәк авылым, мәктәп турында язасы килә.

Әңгәмәдәш – Ләйсән САФИНА

Блиц-сораштыру

– Соңгы укыган китабыгыз?
– Галимҗан Ибраһимовның «Татар хатыны ниләр күрми» әсәрен кабат укыдым.
– Мөмкинлек булса, тормышыгызда нәрсәне үзгәртер идегез?
– Хәзер монда үзгәртерлек нәрсә калмады инде. Дөньям түгәрәк.
– Сезне иң борчыган мәсьәлә?
– Үзем пенсионер булгач, мине пенсионерларның язмышы борчый. Алар эшләп йөрергә мәҗбүр, ә пенсияләре аз, арттырмыйлар. Икенчесе – фатир мәсьәләсе. Хәзер фатир алу бик авыр. Бу аеруча яшьләр өчен проблема.
– Иң бәхетле көнегез?
– Гашыйк булган көнем.
– Кешедә ачуыгызны чыгара торган сыйфат?
– Битарафлык. Әгәр мин ниндидер бер уй, идеягә бирелеп, нәрсәдер эшли башлыйм икән, минем яндагы кешенең битарафлыгын күрсәм, моны бик авыр кичерәм. Янып яшәргә кирәк.

РӘХМӘТЛЕ ЭШ

Илдар Мөхәммәтҗанов

Өлкәннәр ялгызлыктан арыган. Кайберләре үзен тәрбияләүчегә, миндә генә яшә әле, дип тә әйтә икән. Өлкәннәргә ярдәм күрсәтүче социаль хезмәткәрләр аларның барысына да күңел җылысын бирергә тырыша. Һөнәри бәйрәмнәре алдыннан без республиканың төрле районнарында эшләүчеләр белән сөйләштек.

8 июнь – Социаль хезмәткәр көне

ИГЕЛЕКЛЕ КЕШЕЛӘР БӘЙРӘМЕ

Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры Эльмира Зарипова тармак хезмәткәрләрен һөнәри бәйрәмнәре белән котлады.

«Ярдәмгә аеруча мохтаҗларга – өлкәннәргә, балалар, күпбалалы һәм аз керемле гаиләләр, ветераннар, инвалидларга ярдәм кулы сузарга ашыгучыларның бәйрәме бу, – диелә котлауда. – Үзләренең эшен чын мәгънәсендә фидакарьләрчә башкарып килүчеләр бәйрәме!

Бүген республикада 114 социаль хезмәт күрсәтү оешмасы эшли. Тармакта барлыгы 9,6 мең кеше хезмәт куя.

Социаль тармак нинди генә уңышларга ирешмәсен, нинди генә алдынгы технологияләр кулланмасын, аның төп байлыгы – белгечләре. Социаль хезмәткәрләрнең эше гади генә түгел. Әмма аларның һәркайсы ярдәмгә мохтаҗларның тугрылыклы дусты, якын кешесе булырга омтыла. Социаль хезмәткәрләрнең тырышлыгы, игелеклелеге, мәрхәмәтлелеге тормышта авыр хәлдә калучыларга кыенлыкларны җиңәргә ярдәм итә.

Социаль хезмәткәрләрне, тармак ветераннарын һөнәри бәйрәмнәре белән эчкерсез котлыйм! Күп көч, белем һәм вакыт таләп иткән эшегез һәрвакыт шатлык һәм канәгатьлек хисе китерсен! Сезгә нык сәламәтлек, бәхет, тынычлык һәм иминлек телим!»

Өлкәннәр белән уртак тел табу җиңелме? Социаль хезмәткәр эше идән юып, кер үтүкләп, су ташып, утын ярып кына кайту түгел шул. Йөрәгең аша үткәреп, ярдәм иткән кешеңне яратып эшләү дә әле ул. Балтач районының Алан авылында биш әби һәм бер бабайның үз кызына әйләнгән **Гөлчәчәк Гафурова** әнә шулай ди.

– Мин тәрбияләгән өлкәннәрнең балалары читтә яши. Әмма ата-аналары белән даими элемтәдә торалар. Аларны яхшы аңлыйм. Авыл җирендә эш юк, шуңа яшьләр шәһәргә китеп урнаша да ипотекага фатир ала. Аның өчен түләргә кирәк. Баланы бакчага, мәктәпкә йөртмичә дә булмый. Өлкәннәрнең үзләренә дә шулай дип аңлатам. Ана күңеле балада бит инде. Телләрендә гел кыз-уллары, – ди Гөлчәчәк апа.

Күп еллар укытучы булып эшләгән ханымга өлкәннәр белән уртак тел табу кыен булмаган. Эшемне бик яратып башкарам, ди ул. Дөресе дә шул. Яратмасаң, монда эшләп тә булмый. Өлкәннәрнең күңелен алдау мөмкин түгел. Алар һәр карашны сизә, ди Гөлчәчәк апа.

– Мин үземә кушылган сәгать буенча гына эшләмим. Авылдашларымның хәлен еш белешәм. Алар бик тә ялгызлыктан курка. Авырый башласалар, балалар кайтып өлгерерме, дип борчылалар. Олылар белән эшләү тәҗрибә дә, яшәргә дә өйрәтә. Үзебезнең дә картаясы бар бит. Алда ни көткәнне берәү дә белми, – ди ул. – Үз әнием күрше авылда яши. Аңа да социаль хезмәткәр ярдәм итә. Мин дә, үземнең өлкәннәремнең балалары кебек, әнигә булышучы кешегә бик рәхмәтле. Әбиләрем мине үз кызыдай күрә. Үземдә генә яшәтер идем, диюче дә бар. Балаларын югалтканнар исә, каберемә йөреп, догачым булсаң иде, дип васыять әйтеп калдыра. Кыен чакларда да әбиләрем белән киңәшәм. Бер-беребезне аңлап, хөрмәт итеп торабыз. Үзара гармония булганда гына күңелгә рәхәт, җан тыныч.

Кукмара районының Түбән Арбаш авылында яшәүче **Алсу Кәримова**га, өлкәннәр белән уртак тел табар өчен, иң элек татарча өйрәнергә туры килгән. Чиләбедә үскән ханым монда кайтканда бер авыз сүз татарча белмәгән. Әбиләре өйрәткән. Телне генә түгел, үз эшен дә яраткан ул. Өч ел элек Казан дәүләт университетына читтән торып укырга да кергән. Максаты – яхшы хезмәт күрсәтүче белгеч булу.

– Без бит өй җыештырып, кибеттән товар алып кайтып бирүче генә түгел. Заман белән бергә атлыйбыз. «Демография» илкүләм проекты кысасында «Озак вакытлы тәрбияләү» программасы бар. Аның буенча без өлкәннәргә төрле ярдәм күрсәтергә тиеш. Аларны дөрес итеп тәрбияләү, урын өстендә ятучыларга күнегүләр ясату да безнең өстә булачак. Әнә шуңа мин белемемне арттырырга булдым, – ди ул.

Алсуның ире **Марат Кәримов** та 20 елдан артык өлкәннәр карый. Икесенә дә 5әр кеше икән. Холкына карап, кайчак әбиләрне үзара алыштырабыз да, ди Алсу. Әмма үзе тәрбияләгәннәр аның килүен тәрәзәдән карап көтеп тора.

– Бервакыт өлкәннәрне районга алып барып, диспансеризация уздырдык. Шунда минем тәрбиядәге Сәвия апабызның күкрәгендә шеш таптылар. Казан хастаханәсенә дә икәү бергә чыгып киттек. Тикшеренгәч, тиз арада операция кирәклеге ачыкланды. Аллага шөкер, Сәвия апабыз савыкты, – дип искә ала Алсу.

Әбиләрнең дә төрлесе бар икән. Холыклары тиз үзгәрүчәннәренә дә ияләнгәннәр инде. Монысын Марат әйтә.

– Үз авылың кешесен беләсең бит инде ул. Кулдан килгәннең барысын да эшләргә тырышасың. Төрле вакыт була. Әмма өлкәннәрне ачуланып та, аларга үпкәләп тә булмый. Кайбер көнне: «Тагын нинди эшләрегез бар?» – дип кат-кат сорыйм. «Юк», – дип кайтарып җибәрәләр дә соңыннан күршеләреннән ярдәм сорыйлар. Андый чакта кәеф кырыла инде. Әмма күңелне төшереп торып булмый. Мондый очраклар игътибарлы булырга өйрәтә, – ди ул.

Төркәш авылында яшәүче 8 өлкәнгә хезмәт күрсәтүче **Әлфия Сәетгәрәева** күрше авылга җәяү йөреп эшли икән.

– Иремне югалтканга бер ел булды. Элек мине ул йөртә иде. Әмма эшемне ташламадым. Әби-бабаларыма бик ияләнгән идем. Алар янында мин дә онытылып торам, – ди ул.

Яшел Үзәннең психоневрологик диспансерында 34 ел буе хезмәт куючы **Нурия Садыйкова** да социаль хезмәт күрсәтә. Биредә балалары, якыннары баш тарткан, әти-әнисе ташлап калдырган балалар яши. Авырулары да юк түгел. Әмма нинди генә кимчелекләре булса да, күңелләре белән алар да ярату көтә, ди Нурия апа.

– Алар миңа «әни» ди. Яше, карты якын итеп тора. Уртак телне тиз таптык. Һәркайсын үз якыным кебек яратам. Безнең эштә олы йөрәкле, изге күңелле, миһербанлы булу кирәк. Аларның ихлас рәхмәтен ишетү – җанга дәва. Шул рәхмәтләр яшәтә дә инде мине, – ди социаль хезмәткәр.

Һәр социаль хезмәткәр эше турында яратып сөйли. Өлкәннәрне картлык көнендә ялгыз калдырмыйча, яңа һөнәр барлыкка килүгә шатлана алар. Сагынып көтүче кешеләр булуына сөенәбез, диләр. Чит кешенең үз баласыдай якын итүен күреп күңелләре дә тула икән. Кайберләре, ризыклары пешеп чыгуга, кайнар килеш ашасыннар дип, әбиләре янына йөгерә. «Хикмәт акчада гына түгел. Савабы да, рәхмәте дә кирәк», – диләр. Кем әйтмешли, картлык дигәне озак көттермәс, хәзер ишек шакыр.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

САН

Татарстан Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәгълүматларына караганда, бүген республикада 9,6 мең социаль хезмәткәр бар. Алар ел саен 1,5 миллион кешегә хезмәт күрсәтә.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Актив җәмәгать эшчәнлеге алып баруы һәм яшь буынга хәрби-патриотик тәрбия бирүгә мөһим өлеш кертүе өчен «Татарстан Республикасының Диңгез җыены» төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе **Сөнгатов** Шәүкәт Хәнәфи улы **«Дуслык» ордены** белән бүләкләнде.

Татарстан Республикасы Әлки районы Сиктерме-Хузангай авылының исемен үзгәртү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар турында

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ КОРЫЛЫШЫ ҺӘМ ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ КОМИТЕТЫ КАРАРЫ

2022 елның 7 июне, № 1-134-6-ПК

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советының Татарстан Республикасы Әлки районы Сиктерме-Хузангай авылының исемен үзгәртү турындагы мөрәҗәгатен карап, «Географик объектлар исемнәре турында» 1997 елның 18 декабрендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы, «Татарстан Республикасында географик объектлар исемнәре өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2014 елның 23 июлендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Әлки районы Сиктерме-Хузангай авылының исемен үзгәртү мәсьәләсе буенча гавами тыңлауларны 2022 елның 24 июнендә 10 сәгатьтә билгеләргә.

Гавами тыңлауларны үткәрү урынын Татарстан Республикасы Әлки районының «Хузангай клуб-музее» муниципаль учреждениесе бинасы дип билгеләргә, ул түбәндәге адрес буенча урнашкан: Татарстан Республикасы, Әлки муниципаль районы, Сиктерме-Хузангай авылы, Майский урамы, 1А йорт.

2. Гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү өчен түбәндәге составта эшче төркем төзергә:

Хәбибуллин Альберт Галимҗан улы – Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты рәисе;

Билалов Рәшит Әбрар улы – Әлки муниципаль районы башлыгы урынбасары (килешү буенча);

Ибраһимова Лиана Илгиз кызы – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты Хокук идарәсенең конституциячел законнар бүлеге мөдире;

Мотыйгуллина Гөлшат Әмир кызы – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты Оештыру идарәсенең Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге мөдире;

Толмачева Лилия Фаикъ кызы – Әлки муниципаль районы Советының оештыру бүлеге башлыгы урынбасары (килешү буенча).

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советының
Дәүләт корылышы һәм җирле
үзидарә комитеты рәисе А.Г. Хәбибуллин

Яшәеш

Көчле булса, корт бал таба

Быел бал булырмы? Халыкны әнә шул сорау борчый. Май аенда һава торышының көйсезләнеп торуы, умартачыларның да, бал яратучыларның да күңеленә шик салды. Кортларның кышка дигән запас баллары беткән, алар үрчемәгән дип сөйләштеләр. Өстәвенә быел агачлар да соңлап кына чәчәк атты. Белгечләр исә, борчылырлык сәбәп юк, ди.

«Татарстан умартачылары» иҗтимагый оешмасы советы рәисе Шәукәт Хәйруллин да күңелне төшермәскә куша.

– Халыкта бал булмый дигән курку ел саен була инде ул. Узган ел да корылык булгач, балсыз калабыз, дидек. Алдагы елны да һава торышы бик сөендермәде. Әмма бал булды. Дөрес, быел без май аенда бал ала алмадык. Алмагач соң чәчәк атты, – ди ул. – Әле тагын көннәр бозылып тора. Шулай да өметсезләнмәскә кирәк. Юкә – июльдә, карабодай августта чәчәк ата. Җәй алда бит әле. Иң мөһиме – кортларны әзер тотарга кирәк. Бер ояда 70 мең корт булса, балсыз калмыйсың. Алар балны тиз җыя.

Арча районы Ашытбаш авылында яшәүче умартачы Рәис Шәкүровка да: «Быел бал булырмы?» – дип шалтыратучылар күп икән. Ул бал булмас дип борчылмаган да. Күп еллар һава торышын күзәтеп, язып баргач, матур көннәрнең кайчан киләсен чамалый икән. Шуңа күрә кояшлы көннәргә кортларын әзерләп тора. Көчле корт кына бал җыя ала, ди ул. Узган ел кортлары кышлыкка дип куйган балларын ашамаганнар. Әмма кирәге чыккан. Май аенда шуны ашап, көч җыйганнар. Инде кортлары үрчеп, аера да башлаган икән.

– Миңа, кортларым аермый, дип тә киләләр. Умартада бал булса гына кортлар «башка» чыга. Аларга әләктереп чыгарга бал кирәк. Тагын шунысы бар: кортлар иске балны ашап бетермичә, яңасына тими, – ди ул.

Рәис абыйның кортлары быел бал җыеп алырга өлгергән. Алмагач, карлыган, чия кебек җиләк-җимеш куаклары чәчәк атып бетергәч, беренче партия балны суырта да башлыйлар икән. Икенче тапкыр балны август башларында алырга ниятләп торалар. Юкә чәчәгенә өметләре зурдан.

– Бер атна бал җыялар икән, күңел тыныч, бал булачак, – ди ул. – Бал кортлары тәрбияләгәнне ярата. Язга чыгуга, ояларын чистарттым, юдым. Җылытып куйдым. Шулай эшләсәң, кортка уңайлы. Алар бик тырышлар. Кайчак карап торам да шаккатам. Бал алып кайткан кортны нишләтмиләр генә. Бик тәрбиялиләр. Эшче кортны серкәләрдән, тузаннан чистартып чыгарып җибәрәләр. Алар бик башлы да әле. Әгәр оянда бал икмәге (перга) бетсә, үрчемиләр. Корт балаларына бал икмәге генә ашата. Уңыш аласың килсә, кортларны тәрбияләү кирәк. Тагын шунысы бар: көчле корт кирәк. 100 көчсез корт тотканчы, 10 көчлене асрау яхшырак.

Балтач районының Куныр авылында яшәүче Шакирҗановлар белән дә сөйләштек. Иртәдән умарталыкларына барулары иде. Алар да май аенда кортлар оча алмагач, балсыз калабыз, дип борчылганнар, хәзер күңелләре тыныч. Бал кортлары үрчегән. Балтач районында тузганакның матур итеп чәчәк аткан чагы әле, кортлар балны шуннан җыя, диләр.

– Агачлар да әкренләп чәчәк атты. Бар өмет – юкә чәчәгендә. Ул вакытта да җыеп алсалар, балсыз калмабыз, – ди Гөлназ.

Кукмара районының Мәмәшир авылында яшәүче Камил Галиев та балсыз калырбыз дип уйламый. Киресенчә, ел әйбәт килә дип тора. «Бар дөнья чәчәккә күмелде. Быел бал уңышы әйбәт булачак дип уйлыйбыз. Кортларга бал җыярга ике-өч атна җитә», – ди Камил абый.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Белеп торыгыз!

▶ **Юкә балы** бик файдалы, күпләр аны барлык сырхаулардан дәва дип саный. Ул ашкайнату системасын нормальләштерә, ашказаны-эчәк трактындагы ялкынсынуларны бетерә, организмны чистарта, күз күрүен яхшырта, кан әйләнешен активлаштыра.

▶ **Карабодай балы** кан өчен бик файдалы. Бу үсемлекнең нектары аксымнарга бай һәм ул югары сортлы продукт булып санала. Карабодай балында тимер күп, шуңа күрә аны канны яхшырту өчен кулланырга киңәш итәләр. Шулай ук ул азканлылык, ютәл, авитаминоз, ялкынсынудан дәвалануда файда китерәчәк.

▶ **Каштан балы** – каштан чәчәкләреннән җыелган уникаль продукт. Кулинариядә һәм медицинада кулланыла. Тәме әче һәм авызны камаштыра. Нефрит, цистит, йөрәк авыруларыннан, бронхиттан дәвалану өчен куллану киңәш ителә. Каштан балының дезинфекция үзлекләре бар. Аны үт куыгын чистартуда кулланалар.

▶ **Чәчәк балы** катнаш була. Бу продуктның составы төрле. Бал кортлары нектарны төрле чәчәкләрдән – мәтрүшкә, кандала үләне, шалфей, тузганак, люцерна, тукранбаш һәм башкалардан җыя. Мондый бал иммунитетны күтәрү өчен файдалы. Салкын тигәндә, үпкә ялкынсынуы булганда да мондый балның файдасы зур.

ТӨЗЕЛЕШ ҺӘМ РЕМОНТ БРИГАДАСЫ
барлык төрдәге төзелеш эшләрен башкара
ЯЗГЫ ТАШЛАМАЛАР

Үзебезнең яки заказчының материалын кулланабыз.
Коймалар, терраса, фундамент, сайдинг, түбә эшләре, мунча, беседка, хуҗалык корылмалары, өй күтәрү, бүрәнәләрне алыштыру, отмостка, борыс имитациясе эшләре.
Пенсионерларга 15-20% ташлама!
Өйләрне блок-хаус белән тышлау эшләре һ.б.
Мөрәҗәгать иткән көнне үк киләбез!
тел.: 8 968 618 37 78, 8 905 199 99 79
Реклама

ТАЯКНЫ ТАШЛАП... МӘЙДАНГА!

Сабантуйны каршылап

Баулы районының Татар Томбарлысы авылы өлкәннәренең ут уйнатыр чагы җитә. Быредә 57 нче мәртәбә Әбиләр Сабан туе узачак. Бу көнне өлкәннәр яшьлекләренә кайта: 80–90 яшьлек бабайлар – егеткә, әбиләр исә кызга әйләнә. Яшьләр исә олыларның уеннарын гына күзәтеп калмый, киңәшләренә дә колак сала.

Сабан туе узачак мәйданны әзерләүнең бер шарты бар. Үскән үләнне чапмаска! Куе чирәмгә утырып, бәйрәм карау үзе бер рәхәт. Ботаклары җиргә иелеп төшкән каен сәхнә ролен үти. Аның күләгәсендә җырлап, биеп күңел ачалар. Бәйрәмне авыл мулласы Сәйрин Карибуллин азан әйтеп башлый. Клубта оешкан «Хәтирә» фольклор ансамбле ел буе әзерләгән җырларын авыл халкына тәкъдим итә.

– Бу бәйрәм авылда беренче тапкыр 1965 елда салам түбәле ындыр табагында үткән. Авыл Сабан туе еракта узган, әбибабайлар анда бара алмаган. Өлкәннәр читтә калмасын дип, аны Кәшиф абый Солтанов авыл халкы белән бергәләшеп оештырган. Аннан бәйрәм ике тау арасына күчерелгән, хәзер тау битендә уза. Олылар бер-берсе белән рәхәтләнеп аралаша, һәрберсенә игътибар җитә, – ди Татар Томбарлысы авылы мәдәният йорты мөдире Айгөл Нәүрүзбаева. – Кадак кагу, кашык белән йомырка кабып, көянтәчиләк белән йөгерүме, аркан тартышумы, капчык яки мендәр сугышымы, катыктан тимер акча эзләүме... Әйдәгез, дип чакыруга, барысы да уенда катнашырга йөгереп килә. Бернинди ялындырып тору юк. Чүлмәк ватарга яраталар. Табактагы суда биюләр дә әле алар. Кемнең суы беренче бетә, шуңа табак бүләк итәбез. Әбиләрнең ат чабышына әзерләнүе үзе бер кызык. Кулларына чыбыркы тотып, җирне тырнап, кешнәп чабалар. Әлбәттә, чын түгел, уенчык атларда. Бәйрәмгә җыелган барлык әйберне дә таратып бетерәбез. Барысы да гадел уза.

Күңел ачуны гына күздә тотмый бәйрәм. Өлкән буын яшьләр борынгы традицияләрне белсен дип тә тырыша. Авыл агайлары ат җигеп, ат туарып күрсәтә. Әлеге уенны Рәис Гыйбадуллин оештыра икән. Хатын-кызлар да сынатмый. Узган ел Рәисә апа Миңнегулова атны иң оста җигүче булган. Ул татар халык җырларын да бик оста башкара икән. Каен себеркесен (бу якта пиннек диләр. – **Ред.**) бәйләү буенча мастер-класс та күрергә мөмкин. Авылның иң өлкән, иң актив кешесен, иң яшь әбисен билгеләү гадәте дә бар. Фәхриҗамал әби Шәраповага июль аенда 99 яшь тула. Заманасында укытучы булып эшләгән ул. Хәтере бик яхшы, газеталарны яратып укый икән. «Кызлар кебек әле ул, фырт кына киенеп йөри», – дип соклана аңа авылдашлары. Быел Фәхриҗамал әбине дә бүләк көтә, димәк.

Гамир абый Юзаев моңа кадәр бер елны да бәйрәмне калдырмаган.

– Минем кебек ялгыз яшәүчеләр елга бер мәртәбә бәйрәмгә барып кайтса да, бик сөенә. Биергә яратам. Беренче тапкыр тыпырдап кына караган идем, барысы да кул чапты. Менә шуннан бии башладым инде. Көрәштән башка барлык уеннар да була. Әбиләр элек хәтта герләр дә күтәрә иде. Хәзер заманча уеннар өстәлә бара, тик искеләре дә онытылмый. Мәдәният йорты хезмәткәрләре бәйрәмне бик күңелле оештыра, – ди 90 яшьлек Гамир ага.

Сабан туе уздырыла башлаган елларда бәйрәмгә читәннәр, камыштан палас үргән ул. Моның өчен бүләк итеп сәгать биргәннәр аңа. Гамир абый әйтүенчә, мондый бәйрәм ел саен узарга тиеш. Аны һич тә бетерергә ярамый.

87 яшьлек Хаҗәр әби Миңнегәрәева катнашырга дип түгел, тамаша карар өчен бара.

– Без – әбиләр Сабан туен көтеп алабыз. Таякка таянып йөрсәк тә, күңел шунда тартыла. Дөньяга чыгып, авылдашларны күреп, үткәннәрне искә төшерәбез. Көне генә матур булсын инде, – ди Хаҗәр әби.

Гомер буе балаларга белем биргән 77 яшьлек Ризидә апа Бәдриева да бәйрәмне көтеп ала. Күптән түгел Сабан туена дип яулык, сөлге җыйганнар.

– Авыл Сабан туена караганда да күңеллерәк була ул. Аңа ниндидер бер җылылык, ихласлык хас. Баулыдан кадәр карарга киләләр. Шунысы куандыра: миллилек югалмый. Яшь буынның борынгыдан килгән гореф-гадәтләрне белеп үсүе мөһим. Биюче, алып баручылар аякларына чабата кия. Элек көянтә белән су ташу, йомырка кабып йөгерү ярышларында катнаша идем. Җырларга яратам. Хәзер бәйрәмне карарга гына барам. Авылдагы үзгәрешләр турында да белеп кайтабыз. Һәр гаилә үз самавырын алып бара. Соңыннан туганнар белән җыелып, чәй эчәбез. Бу – гаилә кыйммәтләрен саклау чарасы да, – ди Ризидә апа.

Әлеге чараны башка авылларда үткәреп караганнар, тик болай ук килеп чыкмаган. Моның өчен Татар Томбарлысындагы кебек янып торучы әбиләр, бабайлар кирәк шул. Соңгы вакытта Башкортстан галимнәре дә бәйрәм белән кызыксына башлаган икән. Белмим, анысы болай дәвамлы булып китә алырмы? Анысы ни дәрәҗәдә хактыр, Татарстанда башка районда, хәтта Россиядә дә мондый Сабантуй юк, диләр. Татар Томбарлысы өлкәннәре булдыра, чыннан да, маладис!

Сәрия МИФТАХОВА

КЕМНЕҢ ЛИМИТЫ БЕТКӘН, КЕМНЕҢ...

Сабантуйлар җиткәндә, Балтачыбызны бөтен республикада таныткан, матур көрәшләре, үзләренә генә хас алымнары, күпсанлы, мәртәбәле җиңүләре белән район көрәш тарихына кереп калган көрәшчеләребезне искә төшерәм.

Сәбәбе дә бар: бер чорда көрәш белән җенләнеп алган идем. Сабантуйга да көрәш карар өчен генә йөрдем дисәң дә була. Дөрес, еллар үтү белән бу мавыгу үтте, бүген инде аны тыныч кына карый да алмыйм. Әмма теге еллардагы хатирәләр шулкадәр ачык, шулкадәр матур... Инде ул көрәшчеләрнең кайберләрен йөзгә дә танып белмимдер (шактый еллар үтте, барыбыз да үзгәрдек ләбаса), тик бүген дә мин аларның күбесенең келәмгә чыгу, көрәшү рәвешен хәтерлим. Абыйлы-энеле Габделфәрт һәм Илдар Рәфыйковлар, Дамир Сафиуллин, Рифкать Хөсәенов, Рафис Насыйбуллин, Рәдис Галләмов, Сәйдәш Мәгъсүмов, соңрак Айдар Хәйретдинов, Ранил Габдрахманов... Билгеле, легендар көрәшчеләребез болар гына түгел. Алар көрәшкән чорда да, аларга кадәр дә безнең көрәшчеләр республикада иң-иңнәр булды. Муса Җәлил призына үткән ярышларда бүгенгә кадәр әле алар ирешкән биеклекне үтә алучы юк. Балтач феномены булган бу җиңүләр чоры үтү белән ничектер алар да артка чигенде, онытылды шикелле. Бәхеткә, соңгы елларда бәйге-ярышларда, Сабантуйларда кабат аларны искә алалар, мәйдан уртасына чакырып хөрмәтлиләр.

«Дүрт яшьтән бирле көрәштем»

Өч спорт мастеры биргән гаиләдә туып-үскән, данлыклы көрәшче биш бертуганның олысы Фәрит абый Әхмәдиев әнә шулай ди.

– Мин биш тапкыр район Сабан туенда, бишәр тапкыр Малмыж һәм Казанның Совет, бер тапкыр Балык Бистәсе район Сабантуйларында баш батыр булып калдым. Иң беренче зур җиңүем – 16 яшемдә туган авылымда зурлар арасында (ул вакытта үлчәү авырлыклары юк иде) өченче урын алдым. 1966 елда Казанга укырга кергәч, классик көрәш белән шөгыльләнә башладым, 1972 елда Россия чемпионы булдым һәм 1973 елда, районыбыздан иң беренче булып, Россиянең спорт остасы исемен алдым. 1964 елдан 2015 елга кадәр көрәштем дисәм дә, арттыру булмас. Соңгы елларда район Сабантуйларында ветераннар көрәшендә җиңүләр яуладым.

«Көрәшәсе килә, дип кенә мәйданга кереп булмый»

– Мин район Сабан туенда 10 тапкыр баш батыр калдым, ә авылныкыларны санап та бармаганмын, аларның төгәл исәбе дә юк, гомумән, бик күп. Иң беренче тапкыр 2005 елда, унберенче сыйныфны тәмамлаган елны Арборда батыр калдым. Һәр җиңү кадерле булса да, шушы беренче җиңү барыбер аерым хәтердә калды. 9 яшемдә көрәш белән шөгыльләнә башладым. Минһаҗ бабам, әтием, абыем Айнур да көрәшчеләр иде, алардан башка да нәселебездә көрәшчеләр күп, өйдә бу хакта аз сөйләшенмәгәндер. Тренерым Дамир абыйның да роле, йогынтысы бик зур булды, билгеле. Мин Илдар Рәфыйков, Рифкать Хөсәенов, Дамир Сафиуллин, Айдар Гәрәевнең көрәшен бик ярата идем. Хәрәмләшүне белми торган, чиста, матур алымнар белән гадел җиңә торган егетләр иде алар. Үзем дә шулар кебек көрәшергә тырыштым. Көрәштән китүемнең төп сәбәбе чын-чыннан даими шөгыльләнергә вакыт җитмәгәнгә булды, – ди Айдар Хәйретдинов.

«Лимитым беткән булгандыр инде»

– Район Сабан туенда алты тапкыр баш батыр булдым. Бик күп тапкыр авыл Сабантуйларында җиңдем, Казанда Дәрвишләр бистәсендә үткән Сабантуйда икенче урын алдым. Башта классик көрәш белән мавыккан идем. 1984 елда тренерыбыз Васил абый Гарифуллин, әйдә, районга милли көрәшкә барып кара әле, ди. Бер атна шөгыльләндек тә, 75 килограмм авырлыктагылар арасында башта районда җиңдем, аннан Казанда чемпион калдым. Менә шуннан китте инде, – дип искә ала көрәшле елларын Рифкать Хөсәенов. – Иң истә калганы: бер елны район Сабан туена данлыклы пәһлеван Рөстәм Мухамов килде. Баш батыр исеме өчен аның белән көрәшергә туры килде. Ул – 140, мин 100 килограмм идек. Җиңдем бит аны. Ул елларда да бик хәрәмләшкән кешеләр булды. Әнә шундый көндәш туры килгән бер ярышта, ул махсус аягыма төшкәннән соң, җитди имгәнеп, спорттан китәргә туры килде. Дөрес, уңайланганнан соң ун еллап көрәштем, тик элекке дәрәҗәгә кайтып булмады. Иң зур җиңүләрем 80, 100 килограммда булды. Хәзер көрәшәсем килә димәс идем, күрәсең, минем лимит беткән булган.

«Кая барсам да, беренчелекне бирмәдем»

– 1984 елдан 2005 елларга кадәр көрәштем. Беренче тапкыр күрше авыл Сабан туенда тугызынчыны тәмамлаган елны батыр калдым. Шуннан китте инде. Кая барсам да, беренчелекне бирмәдем. Үзебезнең һәм Киров өлкәсе авыллары Сабантуйларында, Питрәчтә, Казанның район Сабантуйларында баш батыр калдым. Бер елны Балтачта Россия күләмендәге Сабантуй үткәрелде. Анда баш батыр өчен бертуган абыем Габделфәрт белән көрәшергә туры килде. Бердәнбер очрак булды ул һәм анда мин җиңдем. Район Сабан туенда биш тапкыр абсолют җиңүче булдым, – дип сөйли Илдар Рәфыйков. – Хәзер дә көрәшне бик яратып карыйм, дүрт улым да көрәшә, Русланыбызның уңышлары шактый инде. Үткән ел район Сабан туенда баш батыр калса, күптән түгел билбау көрәшендә дөнья чемпионы булды.

«Әле дә Сабантуйларга кереп чыгам»

Балтачның тагын бер титуллы көрәшчесе Рәдис Галләмов шулай ди. «Район Сабан туенда мин фәкать бер тапкыр баш батыр калдым. Малмыжда исә өч тапкыр абсолют батыр булдым. Авылларда да шактый җиңдем. Туган авылымда унҗиде тапкыр, тирә-як авылларда ике дистәгә якын батыр калдым. Иң күп җиңүләрем 80 килограммда булды. 85 килограмм авырлыкта исә унбиш җиңүем бар. 80 килограммда өч тапкыр Муса Җәлил призын, дүрт тапкыр Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы беренчелеген оттым, Россия чемпионы булдым. 17 яшемдә Казанда Татарстан беренчелегендә җиңү яуласам да, армиядән кайткач, үзебезнең авыл Сабан туенда батыр калу иң мәртәбәлесе дә, иң сөенечлесе дә булгандыр. 20 ел көрәшкәннән соң, җәрәхәтләр аркасында көрәштән киттем. Әмма әле дә авыл Сабантуйларына кереп чыгам».

«Беренче тапкыр 2005 елда Арборда батыр калдым. Иң кадерле җиңү шул булды», – ди Айдар Хәйретдинов.

«Районда 12 тапкыр баш батыр калдым»

– Көрәшкә мин шактый соңлап, армиядән кайткач, Казан авыл хуҗалыгы институтында укыганда гына килдем. Данлыклы тренер Әсхәт Шәйхетдинов кул астында шөгыльләнә башлагач, ничектер кызыксынып киттем. Иң беренче 1977 елларда үзебезнең авыл Сабан туенда батыр калдым. Баш батырга көрәшү өчен дүрт егет – берсеннән-берсе көчле көрәшчеләр Камил Идрисов, Равил Хәкимов, Вәис Фазылҗанов һәм мин калдык. Аларны җиңә алуым да ышанычны арттыргандыр, – дип искә алды Рафис Насыйбуллин. – Әле институтта бергә укыган дустым Шәйхулла Куликов туган ягына – Чувашиянең Батыр районына кунакка алып кайтты һәм әлеге район Сабан туенда да баш батыр калдым. Хәзер «Ватаным Татарстан» газетасы призына үткәрелүче ярышлар башта «Урожай» спорт җәмгыяте призына оештырыла иде, аны өч тапкыр оттым, Татарстан, Россия беренчелекләрендә җиңүләрем дә шактый. Институтта укыганда ирекле көрәш белән дә мавыгып алдым. 1980 елда Мәскәүгә ярышка баргач, РСФСРның спорт мастеры дигән исемне дә анда алып кайттым. Утыз яшем тулгач туктаган да идем инде, ул чакта район командасының республикада бик тә танылган, бөтен ярышларны диярлек җиңеп барган еллары. Район җитәкчеләре, синең авырлыкта көрәшүче юк, көрәш инде, дигәч, ярышка бардым һәм шунда җитди имгәндем. Вакытында туктыйсы булган, дип үкенәм дә... Бүген көрәш гадел түгел, андый-мондый дигән сүзләр күп ишетелә. Без көрәшкән елларда да шактый булды андый очраклар. Идел буе районындагы Сабантуйда, исемен әйтмим инде, танылган бер көрәшче белән баш батырга бил алышабыз. Мин алып ыргытам, аңа очко бирәләр, мин алып ыргытам, аңа очко бирәләр. Азакка кадәр түздем, тәки чистага салып, баш батыр калдым... Ә улларыма килгәндә, мин аларга көрәшегез димәдем дә. Башта үзләре кызыксынып, шөгыльләнә башлаганнар иде, яшүсмерләр арасында республикада Рәмзил – беренче, Рәмзис икенче урын алганнар, инде җиңүләре дә бар иде. Әмма үзләре үк ташладылар да. Каршы килмәдем, ни дисәң дә, безнең көрәш – спортчының бөтен сәламәтлеген «урлый» торган спорт төре.

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 7057 данә
Гомуми тираж – 16016 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 280

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+